СОВЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

_____________ с. Введенская Слобода _____________

2016 елның 12 гыйнвары № 9-53

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Введенский Бистәсе авыл җирлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 2015 елның 17 декабрендәге 8-47 номерлы карары, Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 2015 елның 17 декабрендәге 18 номерлы карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы

Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советы

карар итте:

1. Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча 2016 елның 6 мартына җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

“Сез 2016 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган ия булган авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Введенский Бистәсе авыл җирлегенең гомуми озынлыгы 10 км булган торак пунктларында 336000 сумлык юлларны ремонтлау.

ӘЙЕ ЮК .

3. Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында “Волжская новь” газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,

Югары Ослан муниципаль районы

Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов